Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кичүчат авыл Советы

КАРАРЫ

13 июль 2022 ел №46

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советының 2022 елның 20 гыйнварендәге 33 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Кичүчат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Кичүчат авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советының 2022 елның 20 гыйнварендәге 33 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада:

а) 2 бүлек 17 статьяның «Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр» өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, федераль законнар белән башкасы билгеләнмәгән булса, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын, башка муниципаль вазыйфаларны, дәүләт яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләргә хокуксыз.»;

б) 19 статья «Депутатның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрен» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарәнең коллегиаль органы әгъзасы булган депутат авыл җирлеге Советы эшчәнлегендә аның актив катнашуын тәэмин итүче тулы хокукларга ия, җирлек Советына аның сайлау округындагы эше турында, җирлек Советына хәбәр итә.

2. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары депутатка аның эшендә кирәкле ярдәмне күрсәтә, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында депутатка хәбәр итә, территорияне икътисадый һәм социаль үстерү программаларын үтәү барышы турында, депутатның тәнкыйть искәрмәләре һәм тәкъдимнәре буенча кабул ителгән чаралар турында хәбәр итә, гамәлдәге

законнарны, авыл җирлеге Советы эше практикасын, җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүгә ярдәм итә.».

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәнең 17 статьясы 3 бүлеге, 2 пункты, а, б пунктчалары, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләрен төзү тәртибенә, вәкаләтләренә һәм аларның статусына, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре әгъзаларының статусына кагылышлы, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре әгъзаларының статусы, Россия Федерациясе закон актлары нигезләмәләренә каршы килмәгән өлешендә, 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләр һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы өлешендә кулланыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Кичүчат авылы, Юлдаш урамы, 2 нче А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кичүчат
авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Шәйхетдинов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КИЧУЧАТОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ОГРН 1021601628335
КИЧУЧАТОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ
ИНН 1644012286
КПП 164401001